КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2022 ел, 13 август

г.Казань

№ 811

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2022 ел, 11 июль, 663 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2022 ел, 11 июль, 663 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 20 июль, 697 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче затларга бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«110,0 мең сум күләмендә, аларның 60,0 мең сумы – гариза бирүче хәрби хезмәт итүгә хәрби часть исемлекләренә кертелгәннән соң, әлеге исемлекләр

Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты тарафыннан һәр дүшәмбе сәгать 10 га кадәр Министрлыкка бирелеп, атна саен 15шәр мең сум күләмендә;»;

өченче абзацта «200,0» саннарын «250,0» саннарына алмаштырырга;

2. Татарстан Республикасы хәрби комиссариатына контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пункты (1 разряд, Казан шәһәре) белән берлектә элек билгеләнгән бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне яңадан исәпләп чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына 2022 елның 15 августының 10.00 сәгатькә кадәр акчаны Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча шәхси счетларына күчерүгә затлар исемлеген тапшырырга.

3. Әлеге карар аңа имза куйган көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 11 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин